# КАЗАН ВӘ КАБАН АРТЫ

## 1.

Кай заманда, кайсы телдә булса да мәзкүр Казан,
Искә керми калмый һич тә шундагы бер күл — Кабан.
Бу шәһәрне һәм бу күлне җырлыйдыр милләт теле
Бик яратып — әллә ичде иске шөһрәт аркылы?
Ул шәһәр гади шәһәр — алтын, көмеш, гәүһәр түгел,
Күл дә тик бер күл генә, әлбәттә, ул кәүсәр түгел.
Нечкәләп баксаң, бу күлнең бар бугай шигърияте,
Бар кеби милләт хыялында аның сиррияте.
Бер вакытлар мин сузып анда Кисек башның җебен[1],
Бер төшеп мендем, бөтенләй тикшереп бактым төбен.
Чыкканым юк тик әле никтер бу күлнең артына,
Әллә мин ялкаулана́ммы? Әллә күңлем тартына?
Тик сөйли күргән кеше анда гараипләр күбен,
Тәңре кылган, ди, гаҗәп бу күлнең артын һәм төбен.

## 2.

Бар имеш, ди, ул күл артында убырның карчыгы,
Йортлы-җирле, ди, үзе, акча тулы, ди, янчыгы.

---

*Булса да мәзкүр* — телгә алынса да.
*Кәүсәр* — сөгле-балды чишмә (дини мифологиядә).
*Сиррияте* — матурлыгы, ясеренлеге.
*Гараипләр* — гаҗәп нәрсәләр.

Ул күл артында адашса кичкә калган кыз бала,
Ихтыярсыз, ди, әбинең йортына ул күз сала.
Ул әбинең балкыган тышка уты бик якты, ди;
Һәм ул ут чиксез матур: күкле, кызыллы, аклы, ди.
Кич белән карчыкка шундый күп адашкан кыз керә,
Чыкмыйлар, ди, юк булалар, ди, тәмам боз күк эреп.
Бер-ике кичне тарыйлар, ди, алар карчык сачын
Һәм кашыйлар, ди, уалар, ди, аягын, аркасын.
Баш таралгач, башлый, ди, ул инде мәлгун касдына,
Хибес итә, ди, барча кызларны идәннең астына.
Ул ябып мазлумәләрне мисле былбыл һәм тавык,
Ташлый, ди, кызлар симерсеннәр дип, анда чикләвек.
Шунда ул кызлар симергәч, ул яга, ди, бер кичен:
Бар тамугтан, бар җәһәннәмнән дә киң һәм зур мичен.
Шул вакыт бер кыз ала, ди, ул чәченнән өстерәп,
Бер кулында, ди, аның дөнья кадәрле зур көрәк.
Әйтә, ди, ул: „Бу көрәккә син утыр, куштан кызым!"
Ташлый, ди, мичкә, утыргач, бер дә чытмастан йөзен.
Ул өй алдында хисапсыз, ди имеш, кыз түшкәсе,
Мөслимә, ди, барчасы, юк бер генә Катюшкасы.
Бер чөйдә торса Рабига, Гайшә, Мәрьям түшкәсе,
Шунда, ди, бергүк эленгән дуңгызы һәм чучкасы.
Шунда кыткылдый әтәч, мыркылдый шунда дуңгызы,
Шундый хурлыкта, хәкарәттә мәхәббәт йолдызы!

---

*Хибес итә* — („хибситә" укыла) ябып куя.
*Мазлумәләрне* — җәберләнгән кызларны.
*Мисле былбыл һәм тавык* — сандугач һәм тавык кебек.
*Мөслимә* — мөселман кызы.
*Катюшкасы* — рус кызы мәгънәсендә.
*Хәкарәттә* — хурлыкта.